КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 2 сентябрь г.Казань № 747

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 20 гыйнвар, 20 нче карары белән расланган Чернобыль АЭСындагы һәлакәт, 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария һәм Теча елгасына радиоактив калдыклар агызу аркасында, шулай ук Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтү буенча тапшырылган вәкаләтне гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган субвенцияләрне тоту кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Чернобыль АЭСындагы һәлакәт, 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария һәм Теча елгасына радиоактив калдыклар агызу аркасында, шулай ук Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтү буенча тапшырылган вәкаләтне гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган субвенцияләрне тоту кагыйдәләрен раслау турында» 2015 ел, 20 гыйнвар, 20 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 6 июль, 557 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Чернобыль АЭСындагы һәлакәт, 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария һәм Теча елгасына радиоактив калдыклар агызу аркасында, шулай ук Семипалатинск

полигонында атом-төш сынаулары аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтү буенча тапшырылган вәкаләтне гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган субвенцияләрне тоту кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

8 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Үзәк Министрлыкка түбәндәгеләрне кертә:

ай саен, аларны күчерү ае алдыннан килүче айның 14енә кадәр, Хезмәт һәм эш белән тәэмин итү федераль хезмәте тарафыннан расланган форма буенча радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтү буенча финанслауның иң чик күләмнәрен ирештерүгә гариза;

квартал саен, хисап чорыннан соң килүче айның 14еннән дә соңга калмыйча, ә хисап елы йомгаклары буенча киләсе финанс елының 19 гыйнварыннан да соңга калмыйча, Россия Федерациясенең Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтү буенча башкарылган касса чыгымнары турында хисап.»;

9 нчы пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ай саен, аларны күчерү ае алдыннан килүче айның 15енә кадәр, Хезмәт һәм эш белән тәэмин итү федераль хезмәте тарафыннан расланган форма буенча радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтү буенча финанслауның иң чик күләмнәрен ирештерүгә гаризаны Хезмәт һәм эш белән тәэмин итү федераль хезмәтенә кертә;»;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«квартал саен, хисап чорыннан соң килүче айның 15еннән дә соңга калмыйча, ә хисап елы йомгаклары буенча киләсе финанс елының 20 гыйнварыннан да соңга калмыйча, Россия Федерациясенең Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтү буенча башкарылган касса чыгымнары турындагы хисапны Хезмәт һәм эш белән тәэмин итү федераль хезмәтенә һәм Россия Федерациясенең Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына кертә;»;

дүртенче абзацта татарча текстта «хисап елыннан соң» сүзләре үзгәрешсез кала, «һәм Россия Федерациясенең Финанс министрлыгына» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«ай саен, хисап аеннан соң килүче айның 10ысыннан да соңга калмыйча, Хезмәт һәм эш белән тәэмин итү федераль хезмәте тарафыннан билгеләнгән форма буенча һәм ысул белән (шул исәптән электрон рәвештә) радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү чараларыннан файдаланучылар реестрын Хезмәт һәм эш белән тәэмин итү федераль хезмәтенә кертә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин